КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 февраль г.Казань № 68

«Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе исемен үзгәртү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе исемен «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә «Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан дәүләт биремнәрен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин